**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2024 елның 9 июле 1118 номер

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлегенең Тарлаши авылында 16:24:050601: 12202 кадастр номерлы җир кишәрлегенә гавами сервитут билгеләү турында**

РФ ЗК 23 маддәсе, 39.37 маддәсе нигезендә, Тарлашы авылында яшәүчеләрнең 2024 елның 28 маендагы Н-1197-АН номерлы күмәк мөрәҗәгатен, //laishevo.tatarstan.ru/hodataystva.htm сылтама буенча урнаштырылган Лаеш муниципаль районының сайттагы хәбәрен карап, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Җир кишәрлекләре аша узу өчен, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектына һәм аның яр полосасына ирекле керүен тәэмин итү максатларында, ачык сервитут билгеләргә, федераль закон нигезендә кадастр номеры 16:24:050601:12202 булган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлегенең Тарлаши авылындагы «Архиерейское» күленә ирекле керү чикләнгән очраклардан тыш, билгеләү срогы-49 ел.
2. Узу юлын урнаштыру максатларында гавами сервитутның кушымта итеп бирелә торган чикләрен расларга.
3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына законнарда билгеләнгән тәртиптә әлеге карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә тәэмин итәргә:

- әлеге карарны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

4. Мөрәҗәгать итүчеләр вәкиле С. Ю. Носовка:

- әлеге карарның күчермәләрен Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, җир кишәрлекләренең хокук иясенә җибәрергә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Э. В. Хисмәтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**